КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 27 март г.Казань № 287

2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасын раслау турында

Россия Федерациясе гражданнарының түләүсез медицина ярдәме күрсәтүгә конституциячел хокукларын тәэмин итү максатларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтү дәүләт гарантияләре программасы турында» 2025 елның 28 декабрендәге 2188 номерлы карарын үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасын (алга таба – Программа) расларга.

2. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

2026 елда Программа кысаларында күрсәтелгән медицина хезмәтләре өчен исәп-хисапларны тәмамлау 2027 елның 15 февраленә кадәр гамәлгә ашырыла;

Программаны гамәлгә ашыруда катнашучы медицина оешмалары тарафыннан Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына һәм «Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды» дәүләт учреждениесенә законнар нигезендә билгеләнгән тәртиптә һәм формалар нигезендә мәҗбүри медицина иминияте өлкәсендәге эшчәнлек турында хисаплылык һәм Программа расланган көннән алып 14 көн эчендә – тиешле финанс елына финанс-хуҗалык эшчәнлеге планнары кертелә;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына түбәндәге вәкаләтләр йөкләнә:

2026 елга Татарстан Республикасының мәҗбүри медицина иминияте территориаль программасы буенча Медицина ярдәменә түләү турында тариф килешүе төзү

буенча;

медицина оешмалары тарафыннан нигездә бер каналлы финанслауны гамәлгә ашыруга мәҗбүри медицина иминияте системасы аша күрсәтелә торган медицина ярдәме күрсәтү тарифларын һәм алар өчен түләү тәртибен эшләү һәм аларны мәҗбүри медицина иминияте системасы аша күбесенчә бер каналлы финанслауны гамәлгә ашыру кысаларында медицина оешмалары тарафыннан күрсәтелгән медицина ярдәме өчен түләү тарифлары комиссиясенә раслауга кертү буенча;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, рәсми сайтта Программаны һәм медицина ярдәменә түләү өчен билгеләнгән тарифларны урнаштыру буенча;

медицина оешмаларының финанс-хуҗалык эшчәнлеге буенча килештерелгән планнарын «Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды» дәүләт учреждениесенә кертүне тәэмин итү буенча;

квалификация күтәрү программалары буенча медицина хезмәткәрләренә өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру, шулай ук медицина җиһазын сатып алу һәм ремонтлау чаралары планын билгеләнгән тәртиптә раслау буенча;

квалификация күтәрү программалары буенча медицина хезмәткәрләренә өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру, шулай ук медицина җиһазын сатып алу һәм ремонтлау чаралары планына кертү өчен чараларны сайлап алу критерийларын раслау буенча.

3. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына һәм «Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды» дәүләт учреждениесенә «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2025 елның 29 ноябрендәге 81-ТРЗ номерлы һәм «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджеты турында» 2025 елның 29 ноябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнарында әлеге максатларга каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә Программаны гамәлгә ашыру чыгымнарын финанс белән тәэмин итүне гамәлгә ашырырга.

4. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына:

2026 елның 1 апреленә кадәр Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының ведомство буйсынуындагы шифаханә-курорт оешмаларына карата Россия Федерациясе Президентының «Ватанны саклаучылар» махсус хәрби операциядә катнашучыларга ярдәм итү буенча дәүләт фондын булдыру турында» 2023 елның 3 апрелендәге 232 номерлы Указының 2 пунктындагы «в» пунктчасының икенче һәм өченче абзацларында күрсәтелгән хәрби хәрәкәтләр ветераннары җибәрелә алган шифаханә-курорт оешмалары исемлеген әлеге ветераннарның сәламәтлеге торышын, шулай ук шифаханә-курорт оешмасының матди-техник базасы торышын һәм өйрәтелгән медицина хезмәткәрләре булуын исәпкә алып билгеләргә;

ведомство буйсынуындагы медицина оешмаларының медицина хезмәткәрләре өчен, шул ук вакытта медицина хезмәткәрләренең эш хакы дәрәҗәсен, аның Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә артуын исәпкә алып, узган елның эш хакы дәрәҗәсеннән түбән булмаган дәрәҗәдә саклап калып, медицина

оешмаларының хезмәт хакы фондлары структурасында хезмәт хакы буенча түләүләр өлешен, компенсация түләүләрен исәпкә алмыйча, 50 проценттан да ким булмаган күләмдә түләүне тәэмин итү. Эш хакы структурасында окладлар өлешен бәяләгәндә, уртача хезмәт хакы исәбеннән чыгып башкарыла торган түләүләр исәпкә алынмый.

5. 2026 елда иминият медицина оешмаларына һәм мәҗбүри медицина иминияте өлкәсендә эшчәнлек гамәлгә ашыручы медицина оешмаларына ай саен аванс бирү иминият медицина оешмаларының һәм медицина оешмаларының заявкалары буенча, медицина оешмаларына аванс бирү аена кадәрге айның 1 нче көненә карата вакытында түләнмәгән кредитор бурычы булмаган очракта, Татарстан Республикасының мәҗбүри медицина иминияте территориаль программасын эшләү комиссиясе карары нигезендә мәҗбүри медицина иминияте буенча медицина ярдәме күрсәтүне финанс белән тәэмин итү өчен бүленгән еллык күләм чикләрендә еллык күләмнең бер бөтен уникедән йөз күләменнән артыграк күләмдә, әмма 2025 елда мәҗбүри медицина иминияте акчасы исәбеннән төп чаралар һәм матди запаслар сатып алу чыгымнарыннан артмаган суммада гамәлгә ашырылырга мөмкин дип билгеләргә.

6. Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетыннан Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына бирелә торган субвенция акчасының календарь ел йомгаклары буенча файдаланылмаган һәм Татарстан Республикасының мәҗбүри медицина иминияте территориаль программасында катнашучы медицина оешмаларының счетлары һәм счетлар реестрлары белән тәэмин ителмәгән, мәҗбүри медицина иминияте полисы бирелгән Россия Федерациясе субъекты территориясеннән читтә иминләштерелгән затларга күрсәтелгән медицина ярдәме өчен исәп-хисаплар белән тәэмин ителгән өлеше, 2027 елның 1 гыйнварыннан башлап, башлангыч медицина-санитария һәм ашыгыч медицина ярдәмен финанслауның җан башына нормативлары составында медицина оешмаларына күчерелгән мәҗбүри медицина иминияте акчасыннан тыш, Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

7. Бу карарның гамәле 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

8. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин